**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5218**
**12.10.2020**

Башкарма комитетның 2020 елның 14 апрелендәге 1827 номерлы карары белән расланган муниципаль-шәхси партнерлык кысаларында спорт объекты төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 14 апрелендәге 1827 номерлы карары белән расланган муниципаль-шәхси партнерлык кысаларында спорт объекты төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны каплау максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктта «муниципаль-шәхси партнерлык кысаларында» сүзләренә кадәр «Демография» милли проекты «Спорт – яшәү нормасы» федераль проектының һәм Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5631 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасының» сүзләрен өстәргә;

2) 6 пунктның 4 пунктчасында «банкротлык» сүзен «аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми

хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.Г. Хамаевага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов